Тамашачыларны Аяз Гыйләҗев «каршы алачак» : [Чаллыда Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев истәлегенә һәйкәл куелачак] // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 9 (11 февраль). – Б. 8.



№ 9 (5245)
11 февраль 2026 ел
Шәһри Чаллы

# Тамашачыларны Аяз Гыйләҗев «каршы алачак»

**Чаллыда Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев истәлегенә һәйкәл куелачак. Аны язучы исемендәге Татар дәүләт драма театры каршындагы мәйданга урнаштырачаклар.**

Татарстан Мәдәният министрлыгы монументның иң яхшы эскизына ачык иҗади конкурс игълан итте. Җиңүче эш буенча язучыга бронзадан һәйкәл куелачак.




Бу карар тирән символик мәгънәгә ия. Аяз Гыйләҗев исемендәге театр – аның исемен йөртүче гади мәйданчык кына түгел. Аның әсәрләре буенча куелган тирән эчтәлекле спектакльләр – мәсәлән, «Җомга көн, кич белән...», «Болан» – сәхнәдә психологик тирәнлек һәм милли үзаңның эталоны булып тора. Шулай итеп, һәйкәл уникаль мәдәни кластер булдырачак: әдип үзенең фикерләре һәм геройлары яшәгән бинага «карап торачак». Бу – таш һәм бронзадан ясалган, мирасны бүгенге көн белән бәйләүче символ булачак.

«Әлеге идея язучының тууына 100 ел тулу уңаеннан барлыкка килде. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының безнең инициативаны хуплавына чиксез шатбыз. Бу безнең эшебезгә югары бәя һәм драматург Гыйләҗевның милли мәдәнияттәге зур ролен тану да. Театр һәм Аяз Гыйләҗев – синонимнар. Һәйкәлне нәкъ менә монда кую – табигый дәвам, хөрмәт белдерү, аның әсәрләре безнең асылыбыз икәнлекне тану. Скульптор тудырган язучы образы үзе кебек үк җылы, зирәк һәм таләпчән булуын телибез, безнең театр да шундый булырга омтыла», – ди театрның сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов.